**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

30.12.2020 № 397

**«Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү өчен товар базарлары исемлеген һәм 2019–2022 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планын («юл картасы») раслау турында» Татарстан Республикасы Президенты боерыгына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү өчен товар базарлары исемлеген һәм 2019–2022 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планын («юл картасы») раслау турында» 2019 елның 31 августындагы 306 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Президентының 2020 елның 7 мартындагы 119 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү базарлары исемлегендә 28 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28. Газ (пропан-бутан катнашмасы һәм метан) белән тәэмин итү базары.»;

2019–2022 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планын («юл картасын») кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын башкаручы** **А.В. Песошин**

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның « 30 » декабрендәге
397 номерлы боерыгына
кушымта

**2019-2022 елларга Татарстан Республикасында конкуренцияне үстерүгә булышлык күрсәтү буенча чаралар планы («юл картасы»)**

**I. 2019-2022 елларга Татарстан Республикасында конкуренцияне үстерүгә булышлык күрсәтү буенча чаралар планына («юл картасына») гомуми тасвирлама**

1.1. Конкуренциягә ярдәм итү Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе белән гарантияләнә, Россия Федерациясенең конституциячел корылышы нигезләренең берсе дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлеше булып тора.

Икътисад тармакларында конкуренцияне үстерү – күп аспектлы бурыч, аны хәл итү шактый дәрәҗәдә – макроикътисадый сәясәттән, уңай инвестиция климаты булдырудан башлап, финанс һәм салым системасын үстерүне, административ һәм инфраструктура каршылыкларын киметүне дә кертеп, гражданнарның хокукларын яклауга кадәр – күп төрле юнәлешләр буенча дәүләт сәясәте уздыру нәтиҗәлелегенә бәйле.

1.2. Әлеге 2019-2022 елларга Татарстан Республикасында конкуренцияне үстерүгә булышлык күрсәтү буенча чаралар планының («юл картасы») (алга таба – Чаралар планы) предметы булып конкуренцияне үстерү өчен махсус, системалы һәм шактый әһәмияте булган конкуренцияне үстерү юнәлешләре тора.

1.3. Конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткечләре һәм чаралар хосусый бизнес өлешенә 2023 елның 1 гыйнварына ирешелергә тиешле тармаклар (өлкәләр, товар базарлары) өчен эшләнелә.

1.4. Конкурентлыкны үстерүнең төп күрсәткечләрен хисаплау Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Россия Федерациясе субъектларында икътисад тармакларында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткечләрен исәпләү методикаларын раслау турында» 2018 елның 29 августындагы 1232/18 номерлы боерыгына нигезләнеп башкарылды.

1.5. Татарстан Республикасында товарлар, эшләр һәм хезмәтләр күрсәтү базарларында конкуренция торышына йогынты ясый торган чараларны үз эченә алган Татарстан Республикасының стратегик һәм программа документлары исемлеге әлеге Чаралар планына кушымтада китерелә.

## II. Татарстан Республикасы икътисадының һәр тармагында (өлкәсендә) (аерым товар базарларында) килеп туган хәлгә һәм аның проблематикасына карата беренчел факттагы мәгълүмат (шул исәптән санлы чагылышта)

2.1. Чаралар планында күрсәтелгән товар базарында барлыкка килгән хәлгә һәм аның проблематикасына карата беренчел факттагы мәгълүмат (шул исәптән санлы чагылышта) китерелә, ул шулай ук түбәндәгеләрне үз эченә ала:

товар базарында хосусый милек рәвешендәге хуҗалык субъектларыөлеше турында мәгълүмат;

агымдагы вәзгыятьне тасвирлап, төп проблемаларны анализлап, товар базарының сыйфатлы үзенчәлекләре.

2.2. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 апрелендәге 768-р номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъектларында конкуренцияне үстерү стандарты (алга таба – Стандарт) таләпләре нигезендә Чаралар планында конкуренция үсешенең төп күрсәткечләренә ирешү өчен мәҗбүри булган күрсәткечләр билгеләнгән. Шул ук вакытта Татарстан Республикасында Стандарт нигезендә билгеләнгән максатчан күрсәткеч әһәмиятенә ирешелгән, әмма хәл итү өчен башкача якын килүне таләп итә торган проблемалары калган берничә базар бар.

2.3. Мәгълүмат алу өчен Монополиягә каршы федераль хезмәт (алга таба – Монополиягә каршы федераль хезмәт) тарафыннан расланган Россия Федерациясе субъектларының икътисад тармакларында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткечләрен исәпләү методикаларында күрсәтелгән чыганаклар кулланылды, аерым алганда:

Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының (алга таба – Татарстанстат) статистика мәгълүматлары;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең профильле (тармак) башкарма органнары мәгълүматы;

салым органнары мәгълүматлары;

Татарстан Республикасының 41 товар базарында конкурентлы мохит торышына Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан Стандарт нигезендә ел саен уздырыла торган мониторинг нәтиҗәләре;

Конкуренцияне үстерүгә булышлык күрсәтү буенча вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан әзерләнгән һәм Татарстан Республикасы Президенты каршында Конкуренцияне үстерүгә булышлык күрсәтү комиссиясе утырышының 2020 елның 6 мартындагы АП-12-76 номерлы беркетмәсе белән расланган 2019 елда Татарстан Республикасының товарлар, эшләр һәм хезмәтләр күрсәтү базарларында конкуренцияле тирәлек торышы һәм аны үстерү турында доклад.

## 1. Мәктәпкәчә белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базары

Мәктәпкәчә белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базарына тасвирлама:

Татарстан Республикасында хосусый милек рәвешендәге 34 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы эшли, аларда 3 507 бала тәрбияләнә.

Мәгариф өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне финанс белән тәэмин итү «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 9 мартындагы 132 номерлы карары белән Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе расланган.

Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 9 мартындагы 132 номерлы карары белән расланган.

Лицензияләнгән хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын субсидияләү аларга лицензия алуга этәргеч бирә һәм мәктәпкәчә белем бирү базарында конкуренция үсешенә ярдәм итә.

Мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләре күрсәтү базарында барлыкка килә торган проблемалар:

халык арасында мәктәпкәчә белем бирүгә канәгатьләндерелмәгән ихтыяҗ булуы.

1.1. Мәктәпкәчә белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткече | Үлчәү берәм-леге | Төп күрсәткеч дәрәҗәсе | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 1.1.1 | Төп гомуми белем бирү программаларын – мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыра торган хосусый белем бирү оешмаларында, шәхси эшкуарларда белем ала торган мәктәпкәчә яшьтәге балаларның гомуми исәбендә төп гомуми белем бирү программаларын – мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыра торган хосусый белем бирү оешмаларында, шәхси эшкуарларда белем алучы мәктәпкәчә яшьтәге балалар өлешен арттыру | Төп гомуми белем бирү программаларын – мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыра торган хосусый белем бирү оешмаларында, шәхси эшкуарларда белем ала торган мәктәпкәчә яшьтәге балаларның гомуми исәбендә төп гомуми белем бирү программаларын – мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыра торган хосусый белем бирү оешмаларында, шәхси эшкуарларда белем алучы мәктәпкәчә яшьтәге балалар өлеше | процент | 1,89, ләкин кимен-дә 1 хосу-сый оешма | 1,90, ләкин кимен-дә 1 хосу-сый оешма | 1,91, ләкин кимен-дә 1 хосу-сый оешма | 1,92, ләкин кимен-дә 1 хосу-сый оешма | $V = \frac{V_n}{V_o} \times 100\%$, биредә: $V_n$ – хисап чорында Татарстан Республикасында төп гомуми белем бирү программаларын – мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыра торган хосусый белем бирү оешмалары (шул исәптән аларның филиаллары) һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү буенча хезмәт күрсәтелгән, мәктәпкәчә яшьтәге укучылар саны; $V_o$ – хисап чорында төп | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | гомуми белем бирү программаларын – мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасындагы барлык белем бирү оешмалары, шәхси эшкуарлар тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү хезмәте күрсәтелгән укучыларның гомуми саны | |

1.2. Мәктәпкәчә белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткечен ирешү чарасы:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәмлеге | Максатчан индикатор күрсәткечләре | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1.2.1 | Яңа шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмаларын ачу, шул исәптән дәүләт-хосусый партнерлык (алга таба – дәүләт-хосусый партнерлык) һәм муниципаль-хосусый партнерлык (алга таба – муниципаль-хосусый | Ачылган хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмалары саны | берәмлек | 3 | 4 | 5 | 6 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Инвестиция |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | партнерлык) механизмнарын да кулланып | | | | | | | | үсеше агентлыгы |

## 2. Балаларга өстәмә белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базары

Балаларга өстәмә белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базарына тасвирлама

2020 елның 1 гыйнварына, Татарстанстат мәгълүматлары буенча, балаларга өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хосусый милек формасындагы ун оешма эшли. Өстәмә белем бирү программалары буенча биш яшьтән алып 18 яшькә кадәрге 3 596 бала шөгыльләнә.

Балаларга өстәмә белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базарында барлыкка килә торган проблема:

өстәмә белем бирү өлешендә дәүләтнеке булмаган сектор оешмаларына консультация ярдәме җитми.

2.1. Балаларга өстәмә белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге | Төп күрсәткеч күрсәткечләре | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 2.1.1 | Балаларга өстәмә белем бирү буенча хезмәт күрсәтү өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлешен арттыру | Балаларга өстәмә белем бирү хезмәтләре күрсәтү өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлеше | процент | 2,4 | 3 | 4 | 5 | $V = \frac{V_n}{V_o} \times 100\%$, биредә: $V_n$– хисап чорында Татарстан Республикасы территориясендә хосусый милек рәвешендәге оешмалар тарафыннан өстәмә белем бирү хезмәтләре | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе (килешү |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | күрсәтелгән балалар саны; $V_o$ – хисап чорында Татарстан Республикасы территориясендә барлык (барлык милек рәвешләрендәге) оешмалар тарафыннан өстәмә белем бирү хезмәтләре күрсәтелгән балаларның гомуми саны | буенча) |

2.2. Балаларга өстәмә белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткеченә ирешү чарасы:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәмлеге | Максатчан индикатор күрсәткечләре | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 2.2.1 | Балаларга өстәмә белем бирүнең хосусый милек рәвешендәге мәгариф оешмалары эшчәнлеген популярлаштыру | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында урнаштырылган өстәмә белем бирү | берәмлек | 3 | 4 | 5 | 6 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Республика |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | оешмаларын төзү һәм алар эшчәнлеге буенча мәгълүмати һәм методик материаллар саны | | | | | | | мәктәптән тыш эшләр үзәге» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча) |

### 3. Гомуми белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базары

Гомуми белем бирү хезмәтләре базарына тасвирлама:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 9 мартындагы 132 номерлы карары белән Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе расланган. 2019 елда хосусый милек рәвешендәге гомуми белем бирү оешмаларының белем бирү эшчәнлегенә киткән чыгымнарын субсидияләүгә Татарстан Республикасы бюджетында 84,7 млн.сум каралган.

Гомуми белем бирү хезмәтләре күрсәтү базарында барлыкка килә торган проблемалар:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары тарафыннан төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хосусый белем бирү оешмаларына дәүләт яисә муниципаль преференцияләр җитәрлек дәрәҗәдә бирелмәгән.

3.1. Гомуми белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткече | Үлчәү берәмлеге | Төп күрсәткеч күрсәткечләре | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 3.1.1 | Төп гомуми белем бирү программаларын – башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында белем алучы укучыларның гомуми исәбендә төп гомуми белем бирү программаларын – башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хосусый белем бирү оешмаларында белем алучылар өлешен арттыру | Төп гомуми белем бирү программаларын – башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында белем алучы укучыларның гомуми исәбендә төп гомуми белем бирү программаларын – башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хосусый белем бирү оешмаларында белем алучылар өлеше | процент | 0,81, ләкин кимендә 1 хосусый оешма | 0,85, ләкин кимендә 1 хосусый оешма | 0,87, ләкин кимендә 1 хосусый оешма | 1, ләкин кимендә 1 хосусый оешма | $V = \frac{V_n}{V_o} \times 100\%$, биредә: $V_n$ – хисап чорында Татарстан Республикасында төп гомуми белем бирү программаларын – башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган хосусый белем бирү оешмаларында (шул исәптән аларның филиалларында) гомуми белем бирү буенча хезмәтләр күрсәтелгән укучылар исәбе; $V_o$ – хисап чорында Татарстан Республикасында | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | төп гомуми белем бирү программаларын – башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган барлык белем бирү оешмаларында (Россия Федерациясенең катнашу өлеше 50% югары булган хуҗалык итүче субъектлардан, федераль дәүләт унитар предприятиеләрен-нән, дәүләт корпорацияләрен-нән, дәүләт компанияләрен-нән, федераль бюджет учреждениеләрен-нән, федераль автоном учреждениеләрдән, федераль казна учреждениеләрен- | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | нән тыш) гомуми белем бирү хезмәтләре күрсәтелгән укучыларның гомуми саны | |

3.2. Гомуми белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткечләренә ирешү чаралары:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәмлеге | Максатчан индикатор күрсәткечләре | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 3.2.1 | Оешмаларга дәүләт аккредитациясе буенча хезмәт күрсәтү срогын кыскарту | Дәүләт аккредитациясе буенча хезмәт күрсәтүнең уртача вакыты | эш көннәре | 33 | 32 | 31 | 30 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 3.2.2 | Яңа хосусый гомуми белем бирү оешмаларын ачу, шул исәптән дәүләт-хосусый партнерлык һәм муниципаль-хосусый партнерлык механизмнарын да кулланып | Ачылган хосусый гомуми белем бирү оешмалары саны | Берәмлек | 1 | 2 | 3 | 4 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Инвестиция үсеше агентлыгы |

## 4. Урта һөнәри белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базары

Урта һөнәри белем бирү хезмәтләрен күрсәтү базарына тасвирлама:

Татарстан Республикасы территориясендә 99 һөнәри белем бирү оешмасы эшли, шул исәптән 88 дәүләт һөнәри белем бирү оешмасы, 11 – дәүләтнеке булмаган һөнәри белем бирү оешмасы. 2020/2021 уку елына укучылар саны 74 меңнән артык кеше тәшкил итә.

2014 елдан башлап ресурс үзәкләрен оештыру программасы гамәлгә ашырыла. Бүгенге көндә 41 ресурс үзәге эшли. Программаны гамәлгә ашыруның җиде елы эчендә республика бюджетыннан барлыгы 5,8 млрд.сум бүлеп бирелгән, шул исәптән капиталь ремонтка – биш млрд.сум, җиһазлар сатып алуга – 810 млн.сум. 2021 елга ресурс үзәкләренең гомуми санын 43 кадәр җиткерү планлаштырыла.

Ресурс үзәкләренең уку биналарында һәм остаханәләрендә капиталь ремонт үткәрелгән, өр-яңа укыту-лаборатория җиһазлары кайтартылган.

Республикада ресурс үзәкләре гариза буенча һәм аларны формалаштыруда реаль катнашып төзелә. Аларның эш нәтиҗәлелегенең төп критерие – предприятие белән тыгыз элемтә, белем бирү оешмасын үстерү стратегиясен эшләүдә катнашу, белем бирү процессын гамәлгә ашырганда үзара хезмәттәшлек итү. Шул рәвешле, бүген һәр ресурс үзәгенә база предприятиеләре ярдәм күрсәтеп тора.

Татарстан Республикасы «Ворлдскиллс» хәрәкәтендә. Ресурс үзәкләре эшенең мөһим юнәлеше – инновацияле белем бирү технологияләрен апробацияләү, «Ворлдскиллс» стандартларын кертү. Татарстан хәрәкәткә 2013 елда Россиянең төбәкләреннән беренчесе булып кушылды. Хәрәкәттә катнашу тарихында республика 2014, 2015, 2019 елларда өч илкүләм чемпионат, шулай ук WorldSkills Kazan 2019 дөнья чемпионатын уздыру урынына әйләнде.

Ресурс үзәкләре – төп катнашучылар ролендә. 2016 елда республикада «Ворлдскиллс» хәрәкәтенең төбәк координация үзәге – «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» автоном коммерциягә карамаган оешмасы төзелде.

2014 елдан башлап Татарстан Республикасында дуаль укыту гамәлгә ашырыла. Бу төр укыту теоретик әзерлекне предприятиедә практик белем белән берләштерүне күздә тота, бу вакытта студентлар уку вакытының яртысыннан да ким булмаган өлешен база предприятиесендә үткәрә һәм аның тулы хокуклы хезмәткәрләре булып тора. Дуаль укытуны гамәлгә ашыру укучыларны заманча житештерү шартларына мөмкин кадәр җайлаштыруга юнәлдерелгән. Бүгенге көндә республикада дуаль система буенча һөнәри белем бирү оешмаларындагы 3 000 артык студент белем ала, аларга 500ләп остаз беркетелгән.

В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең Бөгелмә механика заводы белән берлектә «Бөгелмә машина төзү техникумы» урта һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесендә, «Форд Соллерс» компаниясе белән берлектә «Алабуга политехника көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесендә, «Алнас» ачык акционерлык җәмгыяте белән берлектә «Әлмәт һөнәр көллияте» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесендә дуаль белем бирүне гамәлгә ашыру белем бирү оешмалары белән производство арасында нәтиҗәле хезмәттәшлек итү буенча уңышлы нәтиҗәләр булып тора.

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Хезмәт базарында иң сорала торган, урта һөнәри белем бирүне таләп иткән яңа һәм перспективалы 50 һөнәр исемлеген раслау турында» 2020 елның 26 октябрендәге 744 номерлы боерыгы белән расланган Хезмәт базарында иң сорала торган, урта һөнәри белем бирүне таләп иткән яңа һәм перспективалы 50 һөнәр исемлегеннән (алга таба – «ТОП-50» исемлеге) иң перспективалы һәм кирәкле белгечлекләр һәм һөнәрләр буенча белем бирү программалары кертелә. 2019 елдан башлап, иң перспективалы һәм кирәкле белгечлекләр һәм һөнәрләр буенча 24 белем бирү программасы кертелгән.

Урта һөнәри белем бирү хезмәтләре базарында килеп туган проблемалар:

«Ворлдскиллс» стандартлары буенча демонстрацион имтихан үткәрүгә һәм квалификацияле кадрлар әзерләү мәсьәләләре буенча һөнәри белем бирү оешмаларының кече һәм урта бизнес оешмалары (предприятиеләр) белән хезмәттәшлеген үстерү буенча кирәкле эш алып баруга финанс булмавы.

4.1. Урта һөнәри белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткече | Үлчәү берәмлеге | Төп күрсәткеч дәрәҗәсе | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 4.1.1 | Төп һөнәри белем бирү программаларын – урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында белем алучыларның гомуми | Төп һөнәри белем бирү программаларын – урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында белем | процент | 4 ләкин кимендә 1 хосусый оешма | 4,3, ләкин кимендә 1 хосусый оешма | 4,6, ләкин кимендә 1 хосусый оешма | 5, ләкин кимендә 1 хосусый оешма | $V = \frac{V_n}{V_o} \times 100\%$, биредә: $V_n$ – хисап чорында Татарстан Республикасында төп һөнәри белем бирү | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | исәбендә төп һөнәри белем бирү программаларын – урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хосусый белем бирү оешмаларында белем алучылар өлешен арттыру | алучыларның гомуми исәбендә төп һөнәри белем бирү программаларын – урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы хосусый белем бирү оешмаларында белем алучылар өлеше | | | | | | программаларын – урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган хосусый белем бирү оешмаларында (шул исәптән аларның филиалларында да) урта һөнәри белем бирү буенча хезмәтләр күрсәтелгән укучылар исәбе; $V_o$ – хисап чорында Татарстан Республикасында төп һөнәри белем бирү программаларын – урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган барлык белем бирү оешмаларында (Россия Федерациясенең катнашу өлеше | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | 50% югары булган хуҗалык итүче субъектлардан, федераль дәүләт унитар предприятиеләрен-нән, дәүләт корпорацияләрен-нән, дәүләт компанияләреннән, федераль бюджет учреждениеләрен-нән, федераль автоном учреждениеләрдән, федераль казна учреждениеләренн ән тыш) урта һөнәри белем бирү хезмәтләре күрсәтелгән укучыларның гомуми саны | |

4.2. Урта һөнәри белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткечләренә ирешү чаралары:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәм-леге | Максатчан индикатор дәрәҗәсе | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 4.2.1 | Татарстан Республикасында | «Яшь профессионаллар | берәмлек | 35 | 36 | 37 | 38 | Абсолют | Татарстан |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «Ворлдскиллс» махсуслаштырылган компетенцияләр үзәкләрен аккредитацияләү эшләрен үткәрү | (Ворлдскиллс Россия)» берлеге тарафыннан аккредитацияләнгән «Ворлдскиллс» компетенцияләренең махсуслаштырылган үзәкләре саны) | | | | | | күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 4.2.2 | Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү оешмаларының матди-техник базасын үстерү | һөнәри белем бирү оешмаларының матди-техник базасын үстерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы акчасы күләмен саклау | млн.сум | 670,2 | 788,3 | 788,4 | 788,5 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 4.2.3 | «Ворлдскиллс» стандартлары буенча демонстрацион имтихан оештыру һәм үткәрү | «Ворлдскиллс» стандартлары буенча демонстрацион имтиханны тапшырган, Татарстан Республикасының белем бирү оешмаларында укытуның көндезге формасы буенча белем алучылар саны | кеше | 5 750 | 5 800 | 5 850 | 9 600 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

## 5. Югары белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базары

Югары белем бирү хезмәтләре базарына тасвирлама:

2018-2019 уку елында Татарстан Республикасы территориясендә 46 югары белем бирү оешмасы, шул исәптән белем бирүнең 26 төп оешмасы, югары белем бирә торган мәгариф оешмаларының 20 филиалы белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашырган.

Югары белем бирү программалары буенча 146 823 студент белем ала, шул исәптән югары белем бирү дәүләт мәгариф оешмаларында (филиаллары белән) – 126 544, дәүләтнеке булмаган югары белем бирү оешмаларында

(филиаллары белән) 20 279 студент белем ала.

Татарстан Республикасы югары белем бирү оешмаларында югары белем бирүнең бакалавр юнәлеше буенча эреләндерелгән 54 төркеменең 53ендә укыту алып барыла.

2019-2020 уку елында дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче мәгариф оешмалары арасында ачык гавами конкурс нәтиҗәләре буенча югары белем бирүче мәгариф оешмаларына федераль бюджеттан кабул итү буенча 16 312 контроль саны (алга таба – кабул итү буенча контроль сан) бүлеп бирелгән, шуларның 63 проценты – югары белем бирүгә әзерлекнең инженер-техник юнәлешләренә, 27 проценты – гуманитар юнәлешләренә, 10 проценты – табигый-фәнни юнәлешләренә.

Югары белем бирү хезмәтләре базарында барлыкка килә торган проблемалар:

аккредитацияләнгән белем бирү программаларын кыскарту;

дәүләтнеке булмаган югары белем бирү оешмалары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган әзерлек юнәлешләре түбән.

5.1. Югары белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткече | Үлчәү берәмлеге | Төп күрсәткеч дәрәҗәсе | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 5.1.1 | Хосусый милек рәвешендәге югары белем бирү оешмалары өлешен арттыру | Хосусый милек рәвешендәге югары белем бирү оешмалары өлеше | процент | 40 | 40,1 | 40,2 | 40,3 | $V = \frac{V_n}{V_o} \times 100\%$, биредә: $V_n$ – Татарстан Республикасы территориясендә югары белем бирүче хосусый милек формасындагы оешмалар саны; | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | $V_o$ – Татарстан Республикасы территориясендә югары белем бирү буенча хезмәт күрсәтүче барлык (барлык милек рәвешләрендәге) оешмаларның гомуми саны | |

5.2. Югары белем бирү буенча хезмәт күрсәтү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткеченә ирешү чаралары:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәм-леге | Максатчан индикатор дәрәҗәсе | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 5.2.1 | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан хосусый милек рәвешендәге югары белем бирү оешмаларына гамәлдәге республика һәм федераль программалар, проектлар турында мәгълүмат җиткерү | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан хосусый милек рәвешендәге югары белем бирү оешмалары – республика һәм федераль программаларда, проектларда катнашучылар саны | берәмлек | 3 | 4 | 5 | 6 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.2.2 | Татарстан Республикасы икътисадының квалификацияле кадрларга ихтыяҗларын һәм халык арасында белем бирү буенча хезмәт күрсәтүгә булган сорауны исәпкә алып, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан хосусый милек формасындагы югары белем бирүче мәгариф оешмаларына бүлеп бирү өчен планлаштырыла торган кабул итү буенча контроль сан күләмнәре буенча Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгына тәкъдимнәр юллау | Федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укыту өчен кабул итү буенча контроль сан ала торган, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, хосусый милек формасындагы югары белем бирүче мәгариф оешмалары саны | берәмлек | 4 | 5 | 6 | 7 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |

## 6. Җылылык белән тәэмин итү (җылылык энергиясе җитештерү) базары

Җылылык белән тәэмин итү (җылылык энергиясе җитештерү) базарына тасвирлама:

2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында җылылык белән тәэмин итү хезмәтен 75 оешма тарафыннан күрсәтелә. Шуларның 42се хосусый милек формасындагы оешма (44се – филиалларын исәпкә алып). Хосусый милек формасындагы оешмалар өлеше 56 процент тәшкил итә (филиалларны исәпкә алып, 58,6 процент). Әлеге күрсәткеч әлеге базарның төп күрсәткеченнән шактый югары, бу исә республиканың коммуналь комплексында дәүләт-хосусый партнерлык программаларын актив гамәлгә ашыру нәтиҗәсе булып тора.

2019 елда Татарстан Республикасы оешмаларыннан җибәрелгән җылылык энергиясенең гомуми күләме 40 197,31 мең Гкал тәшкил иткән, шул ук вакытта хосусый оешмалар өлешенә 27 357,04 мең Гкал туры килә, бу сатылган җылылык энергиясенең 68,1 процентын тәшкил итә.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасының җылылык белән тәэмин итү базары коммуналь объектларның һәм инженерлык коммуникацияләренең югары дәрәҗәдә искергән булу белән характерлана. Коммуналь инфраструктура объектларының һәм корылмаларының әхлакый һәм физик яктан югары дәрәҗәдә тузган булуы җәмгыятьнең, шул исәптән яңа торак төзелеше һәм яңа социаль инфраструктура объектлары төзелеше белән бәйле, арта барган ихтыяҗларын тәэмин итми. Коммуналь челтәрләрнең тузуы шулай ук авария хәлләренә китерә. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының авария-техник запасларыннан материаллар һәм җиһазлар бүлеп бирү үтенече белән ел саен торак-коммуналь хуҗалык өлкәсе оешмаларыннан 200 артык мөрәҗәгать килә.

Күпчелек оешмалар республиканың авыл районнарында коммуналь фондлар буларак оештырылган һәм эшли, алар хосусый инвесторларда кызыксыну тудырмый. Мондый оешмаларның төп кулланучылары – авыл җирендә яши торган, түләү сәләте зур булмаган халык һәм бюджет оешмалары.

Коммуналь объектларның инвестиция җәлеп итү дәрәҗәсе түбән булганда, шул исәптән коммуналь хезмәтләр өчен гражданнарның түләвен арттыруга гамәлдәге чикләүләргә бәйле рәвештә дә, хосусый инвесторларны җәлеп итү буенча башкарылган эш нәтиҗәсендә Татарстан Республикасында ирешелгән күрсәткечнең максатчан әһәмиятен киметмәү мөһим.

Җылылык белән тәэмин итү (җылылык энергиясе җитештерү) базарында барлыкка килә торган проблемалар:

төп фондларның нык тузган булуы;

күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты җитәрлек дәрәҗәдә булмавы.

6.1. Җылылык белән тәэмин итү (җылылык энергиясе җитештерү) базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткече | Үлчәү берәмлеге | Төп күрсәткеч дәрәҗәсе | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 6.1.1 | Җылылык белән тәэмин итү (җылылык энергиясе җитештерү) өлкәсендә хосусый милек | Җылылык белән тәэмин итү (җылылык энергиясе җитештерү) өлкәсендә хосусый | процент | 70 | 68,3 | 68,5 | 68,7 | $V = \frac{V_n}{V_o} \times 100\%$, биредә: $V_n$ – | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | формасындагы оешмалар өлешен арттыру | милек формасындагы оешмалар өлеше | | | | | | хосусый милек формасындагы оешмалар тарафыннан җылылык энергиясен файдалы җибәрү күләме, мондый оешмалар дигәндә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлек катнашуның җыелма өлеше булмаган яки иң күбе 50 процент (Гкал) тәшкил итә торган хуҗалык субъектлары турында сүз бара; $V_o$ – бу барлык хуҗалык субъектлары(Россия Федерациясе катнашу өлеше 50 проценттан артык булган хуҗалык итүче субъектлардан, федераль дәүләт унитар | һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | предприятиеләрен-нән, дәүләт корпорацияләрен-нән, дәүләт компанияләреннән, федераль бюджет учреждениеләрен-нән, федераль автоном учреждениеләрдән, федераль казна учреждениеләрен-нән тыш) тарафыннан җылылык энергиясен файдалы җибәрү күләме (Гкал) | |

6.2. Җылылык белән тәэмин итү (җылылык энергиясе җитештерү) базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткеченә ирешү чарасы:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәм-леге | Максатчан индикатор дәрәҗәсе | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 6.2.1 | Концессия килешүләре нигезендә җылылык белән тәэмин итү объектларын хосусый операторларга идарәгә тапшыру | Концессия килешүләре нигезендә хосусый операторларга тапшырылган җылылык белән | берәмлек | 324 | 326 | 328 | 330 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | тәэмин итү объектлары саны | | | | | | | хуҗалыгы министрлыгы |

## 7. Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау хезмәтләре базары

Каты коммуналь калдыкларны (алга таба – ККК) җыю һәм транспортлау буенча хезмәтләр күрсәтү базарының тасвирламасы:

ел саен республикада ККК белән эш итү объектларына транспортлана торган 12 000 мең куб.метрдан артык ККК барлыкка килә. 2019 елда ККК транспортлауны гамәлгә ашыручы хосусый милек формасындагы оешмалар өлешенә ККК җыю һәм транспортлау буенча хезмәтләр күрсәтү базарының гомуми күләменнән 89 проценты туры килә.

«Житештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү, шулай ук каты коммуналь калдыкларны транспортлау каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары (Россия Федерациясе законнары нигезендә конкурс аша сайлап алу нәтиҗәләре буенча каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы статусы бирелгән юридик затлар) тарафыннан тәэмин ителә.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 25 августындагы 641 номерлы карарына үзгәреш кертү турында»гы 2016 елның 12 ноябрендәге 1156 номерлы карары белән расланган Ккаты коммуналь калдыклар белән эш итү кагыйдәләре нигезендә, төбәк операторы, мөстәкыйль рәвештә яисә каты коммуналь калдыклар белән эш итүче операторларны (каты коммуналь калдыклар белән эш итүче хуҗалык субъектларын) җәлеп итеп, каты коммуналь калдыклар белән эш итә, шул исәптән аларны җыя һәм транспортлый.

Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау хезмәтләре күрсәтү базарында барлыкка килә торган проблемалар:

Татарстан Республикасында каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау төбәк операторлары тарафыннан тәэмин ителә, алар закон нигезендә каты коммуналь калдыкларны мөстәкыйль рәвештә яки транспортлау буенча операторларны җәлеп итеп башкара (транспортлау буенча операторларның бер өлеше электрон сатулар буенча җәлеп ителә). Шул рәвешле, каты коммуналь калдыкларны җыю һәм мөстәкыйль транспортлау буенча төбәк операторлары тарафыннан хезмәтләрнең максималь күләме күрсәтелгән очракта, каты коммуналь калдыкларны транспортлау базарында милекчелекнең хосусый формасындагы оешмалар санының кимү куркынычы бар.

7.1. Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау хезмәтләре күрсәтү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткече | Үлчәү берәм-леге | Төп күрсәткеч дәрәҗәсе | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 7.1.1 | Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау хезмәтләре күрсәтү өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлешен арттыру | Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау хезмәтләре күрсәтү өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлеше | процент | 89,90 | 89,91 | 89,92 | 89,93 | $V = \frac{V_n}{V_o} \times 100\%$, биредә: $V_n$– хосусый милек формасындагы оешмалар тарафыннан транспортлана торган ККК күләме, мондый оешмалар дигәндә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлекнең уртак катнашу өлеше булмаган яки иң күбе 50 процент (куб.м) тәшкил итә торган хуҗалык субъектларытурында сүз бара; $V_o$ – бу барлык | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | **хуҗалык субъектлары (Россия Федерациясе катнашу өлеше 50 проценттан артык булган хуҗалык субъектларыннан, федераль дәүләт унитар предприятиеләреннән, дәүләт корпорацияләреннән, дәүләт компанияләреннән, федераль бюджет учреждениеләреннән, федераль автоном учреждениеләрдән, федераль казна учреждениеләреннән тыш) тарафыннан транспортлана торган каты коммуналь калдыклар күләме (куб.м)** | |

7.2. Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау хезмәтләре базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткеченә ирешү чарасы:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәмлеге | Максатчан индикатор дәрәҗәсе | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 7.2.1 | Каты коммуналь калдыкларны транспортлау буенча яңа шәхси инициативаларга этәргеч бирү | Гамәлдәге һәм потенциаль эшкуарлар һәм коммерция оешмалары белән түгәрәк өстәлләр, вебинарлар, консультацияләр үткәрү | берәмлек | 3 | 4 | 5 | 6 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, каты коммуналь калдыклар белән эш итүче төбәк операторлары (килешү буенча) |

## 8. Күпфатирлы йортта торак урыннар милекчеләренең гомуми милкен карап тоту һәм аларның агымдагы ремонты буенча эшләр башкару базары

Күпфатирлы йортта торак урыннарның милекчеләренең гомуми милкен карап тоту һәм аларның агымдагы ремонты буенча эшләр башкару базарының тасвирламасы:

2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында идарәче компанияләр карамагында булган күпфатирлы йортларның (алга таба – күпфатирлы йортлар) гомуми мәйданы – 50 194,4 мең кв.метр, шулардан муниципаль милек рәвешендәге идарәче компанияләр (алга таба – идарәче компания) идарәсендә – 1 004,9 мең кв.метр; хосусый милек

рәвешендәге идарәче компанияләр идарәсендә – 49 189,5 мең кв.метр. Чагыштыру өчен: 2019 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында идарәче компанияләр карамагында булган күпфатирлы йортларның гомуми мәйданы – 49 469,1 мең кв.метр, шулардан муниципаль милек рәвешендәге идарәче компанияләр (алга таба – идарәче компания) идарәсендә – 259,0 мең кв.метр; хосусый милек рәвешендәге идарәче компанияләр идарәсендә – 49 210,1 мең кв.метр.

2020 елның 1 гыйнварына республикада 272 идарәче компания эшли, шуларның 14е – муниципаль милек формасындагы идарәче компания.

Шактый зур финанс агымнары, идарә системасының ачык аңлашлы булмавы торак-коммуналь хуҗалык өлкәсен, шул исәптән күпфатирлы йортта биналар милекчеләренең гомуми милкен карап тоту эшләрен дә, коррупциячел-куркыныч өлкәләргә кертә.

Торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр өлкәсендәге проблемалар турында гражданнар мөрәҗәгатьләрен электрон рәвештә бастырып чыгару мөмкинлекләрен киңәйтү килеп туган проблемаларны оператив хәл итәргә мөмкинлек бирә. Мондый элемтә формасы Татарстан Республикасы халкына кирәк. Татарстан Республикасының «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы мәгълүматлары буенча, торак-коммуналь хезмәтләр өлкәсендәге проблемалар турында гражданнарның басылып чыккан мөрәҗәгатьләре саны арта. Гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә идарә итү һәм операция процессларын оештыру нәтиҗәлелеген күтәрүдә төп юнәлешләрне билгеләргә мөмкинлек бирә.

Күпфатирлы йортта торак урыннарның милекчеләренең гомуми милкен карап тоту һәм аларның агымдагы ремонты буенча эшләр башкару базарында барлыкка килә торган проблемалар:

күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты түбән;

күпфатирлы йортларны карап тотуны яхшырту һәм ишегалды территорияләренең уңайлылыгын арттыру ихтыяҗы.

8.1. Күпфатирлы йортта биналар милекчеләренең гомуми милкен карап тоту һәм агымдагы ремонт буенча эшләр башкару базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткече | Үлчәү берәмлеге | Төп күрсәткеч дәрәҗәсе | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 8.1.1 | Күпфатирлы йортларда биналар милекчеләренең гомуми милкен карап тоту һәм агымдагы ремонтлау эшләрен башкару өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлешен саклап калу | Күпфатирлы йортларда биналар милекчеләренең гомуми милкен карап тоту һәм агымдагы ремонт эшләрен башкару өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлеше | процент | 99 | 99 | 99 | 99 | $V = \frac{V_n}{V_o} \times 100\%$,<br>биредә: $V_n$– күпфатирлы йорттагы биналар милекчеләренең гомуми милек составына керүче, хосусый милек формасындагы оешмалар (торак милекчеләре ширкәтләреннән, торак, торак-төзелеш кооперативларыннан яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларыннан, шулай ук күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы турыдан-туры идарә итү ысулыннан тыш) | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | карамагында булган биналарның гомуми мәйданы;<br>$V_o$ – бу күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган (Россия Федерациясенең катнашу өлеше 50 проценттан артык булган хуҗалык итүче субъектлардан, федераль дәүләт унитар предприятиеләреннән, федераль бюджет учреждениеләреннән, федераль автоном учреждениеләреннән, федераль казна учреждениеләреннән тыш) барлык хуҗалык субъектлары(торак милекчеләре ширкәтләреннән, торак, торак-төзелеш кооперативларыннан яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларыннан, | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | шулай ук турыдан-туры идарә итү ысулыннан тыш) идарәсендә булган күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең гомуми милеге составына керә торган биналарның гомуми мәйданы | |

8.2. Күпфатирлы йортта биналар милекчеләренең гомуми милкен карап тоту һәм агымдагы ремонт эшләрен башкару базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткеченә ирешү чарасы:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәмлеге | Максатчан индикатор дәрәҗәсе | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 8.2.1 | Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә югары квалификацияле белгечләр әзерләү юлы белән күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту | Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә әзерлек, яңадан һөнәри әзерлек һәм квалификация күтәрүне узган кешеләр саны | кеше | 3128 | 3129 | 3130 | 3131 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |

9. Дару препаратларын, медицина эшләнмәләрен һәм башка кирәкле товарларны ваклап сату хезмәте күрсәтү базары

Дару препаратларын, медицина эшләнмәләрен һәм кирәкле башка товарларны ваклап сату хезмәте күрсәтү

базарының тасвирламасы:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | Республикасында фактта социаль хезмәтләр күрсәткән барлык (барлык милек формасындагы) социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының (Россия Федерациясе катнашу өлеше 50 проценттан артык булган хуҗалык субъектларыннан, федераль дәүләт унитар предприятиеләрен-нән, дәүләт корпорацияләрен-нән, дәүләт компанияләрен-нән, федераль бюджет учреждениеләрен-нән, федераль автоном учреждениеләрдән, федераль казна учреждениеләрен-нән тыш) саны | |

18.2. Социаль хезмәтләр күрсәтү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткеченә ирешү чарасы:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәмлеге | Максатчан индикатор дәрәҗәсе | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 18.2.1 | Социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр реестрына керү турында дәүләтнеке булмаган оешмаларга мәгълүмат җиткерү буенча консультацияләр үткәрү, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләтнеке булмаган оешмаларга методик ярдәм күрсәтү | Социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына керү буенча дәүләтнеке булмаган оешмаларга мәгълүмат җиткерү буенча консультацияләр үткәрү, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләтнеке булмаган оешмаларга методик ярдәм күрсәтү | Булу-булмавы | әйе | әйе | әйе | әйе | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |

## 19. Мәдәният өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү базары

Мәдәният өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү базарының тасвирламасы:

Татарстан Республикасында шактый мәдәни потенциал тупланган, 2019 елда:

театр сәнгате өлкәсендә 18 дәүләт һәм муниципаль театр эшләде. Моннан тыш, республикада даими нигездә дәүләтнеке булмаган ун театр эшләде. Кинематография өлкәсендә 148 кино күрсәтү ноктасы, халыкка даими рәвештә кино-видео хезмәте күрсәтә торган 25 күчмә кино җайланмасы эшчәнлек алып барды. Концерт эшчәнлегендә 19 концерт оешмасы эшләде, биш виртуаль концерт залы булдырылды. Цирк эшендә ике цирк чыгыш ясады. Музей эшендә 173 дәүләт һәм муниципаль музей челтәре берәмлеге, алты шәхси музей эшләде, цифрлы гид белән тәэмин

ителгән бер күргәзмә проекты (Татарстан Республикасы Милли музееның мультимедиа-гиды) төзелде, шулай ук 2 567 күргәзмә үткәрелде. Китапханә-мәгълүмат эшчәнлегендә республика халкы арасында мәдәни-агарту эшләрен гавами 1 512 китапханә, шулай ук ике модель китапханәсе башкарды. Мәдәни-ял итү эшчәнлегендә 1 933 мәдәни-ял итү тибындагы учреждение исәпләнә. Мәдәният өлкәсендә 117 мәгариф оешмасыннан (105 өстәмә белем бирү оешмасыннан, тугыз һөнәри белем бирү оешмасыннан, ике югары белем бирү оешмасыннан, бер өстәмә һөнәри белем бирү оешмасыннан) торган челтәр эшли.

Мәдәният учреждениеләрнең күп төрле булуына карамастан, кайбер өлкәләрдә оешмаларның гомуми исәбендә дәүләткә карамаган (муниципаль булмаган) оешмаларның өлеше аз булуы, шуның нәтиҗәсе буларак конкуренциянед түбән дәрәҗәсе күзәтелә.

Мисал өчен, китапханә һәм мәдәният-ял үзәкләре хезмәтләре базарларында конкуренция түбән дәрәҗәдә. Китапханә хезмәтләре күрсәтүне һәм муниципаль оешмаларның мәдәният-ял үзәкләрендә хезмәтләр күрсәтүне 100 процентлы итеп оештыру дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла, чөнки бу өлкәдә конкуренцияне үстерү табигый сәбәпләр аркасында чикләнгән.

Конкуренция дәрәҗәсе театр һәм музей хезмәтләре кебек сегментларда уртача дип бәяләнә.

Татарстан Республикасының мәдәни киңлеген чагыштырма анализлау Татарстан Республикасы халкының төрле мәдәният учреждениеләре хезмәтләре белән тәэмин ителеше дәрәҗәсен һәм аларның ихтыяҗ рейтингын билгеләргә мөмкинлек бирде.

Мәдәният өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү базарында барлыкка килә торган проблемалар:

мәдәният өлкәсендәге оешмаларның гомуми исәбендә хосусый милек формасындагы оешмаларның өлеше кечкенә булу;

мәдәният учреждениеләрендә күрсәтелә торган хезмәтләр күләме һәм төрләре гражданнарның ихтыяҗларына, көткән һәм өмет иткән нәрсәләргә тулы күләмдә җавап бирмәве.

19.1. Мәдәният өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткече | Үлчәү берәм-леге | Төп күрсәткеч дәрәҗәсе | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 19.1.1 | 2022 елга мәдәният өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыру һәм хезмәтләр күрсәтү өчен бүлеп бирелә торган акчаның гомуми күләмендә хосусый милек формасындагы оешмаларга бүлеп бирелә торган бюджет акчалары өлешен арттыру | 2022 елга мәдәният өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү һәм проектларны гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелә торган акчаның гомуми күләмендә хезмәт күрсәтү һәм проектларны гамәлгә ашыру өчен хосусый милек формасындагы оешмаларга бүлеп бирелә торган бюджет акчалары өлеше | про-цент | 10,4 | 10,5 | 10,6 | 10,7 | $V = \frac{V_n}{V_o} \times 100\%$, биредә $V_n$ – мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыру һәм чаралар үткәрү өчен дәүләтнеке булмаган оешмаларга бүлеп бирелә торган Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты акчалары күләме, млн.сум; $V_o$ – мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыру һәм чаралар үткәрүгә бүлеп бирелә торган Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджет | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | **акчаларының гомуми күләме, млн.сум** | |

19.2. **Мәдәният өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткечләренә ирешү чаралары:**

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәмлеге | Максатчан индикатор дәрәҗәсе | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 19.2.1 | **Мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыру һәм чаралар уздыру өчен дәүләтнеке булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү** | **Мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыру һәм чаралар үткәрү өчен дәүләтнеке булмаган оешмаларга бүлеп бирелә торган бюджет акчалары өлеше** | **процент** | 10,4 | 10,5 | 10,6 | 10,7 | $V = \frac{A}{B} \times 100\%$, **биредә: A – мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыру һәм чаралар үткәрү өчен дәүләтнеке булмаган оешмаларга бүлеп бирелә торган Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты акчалары күләме, млн.сум; B – мәдәният өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыру һәм чаралар үткәрүгә бүлеп** | **Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы** |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | бирелә торган Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты акчаларының гомуми күләме, млн.сум | |
| 19.2.2 | Халыкның мәдәният өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрдән канәгать булу дәрәҗәсен ачыклаумаксатында ел саен социологик тикшеренүләр уздыру | Мәдәният өлкәсендә халыкның хезмәтләр сыйфатыннан канәгать булу дәрәҗәсе | процент | 98 | 99 | 99 | 99 | $V = \frac{A}{B} \times 100\%$, биредә: Шулай ук мәдәният өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфатын уңай бәяләүче гражданнар саны, берәмлек; В – сораштыруда катнашкан гражданнарның гомуми саны, берәмлек | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (килешү буенча) |

20. Элемтә хезмәтләре күрсәтү, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән киң полосалы файдалану мөмкинлеген бирү буенча хезмәтләр күрсәтү базары

Элемтә хезмәтләре күрсәтү, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән киң полосалы файдалану мөмкинлеген бирү буенча хезмәтләр күрсәтү базарының тасвирламасы:

Татарстан Республикасында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән киң полосалы файдалану мөмкинлеген бирү буенча хезмәт күрсәтү өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлеше 100 процент тәшкил итә.

Элемтә хезмәтләре күрсәтү, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән киң полосалы файдалану мөмкинлеген бирү буенча хезмәтләр күрсәтү базарында барлыкка килә торган проблемалар:

торак пунктларда телекоммуникация инфраструктурасы җитәрлек дәрәҗәдә үсеш алмаган;

торак пунктларда элемтә хезмәте бары тик бер элемтә операторы тарафыннан гына күрсәтелә яки әлеге хезмәттән файдалану мөмкинлеге бөтенләй юк.

Әлеге проблема телекоммуникация хезмәтләренең территориаль яктан, бәясе һәм сыйфаты буенча кулланучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә йогынты ясый, эшкуарлык активлыгын тоткарлый.

20.1. Элемтә хезмәтләре күрсәтү, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән киң полосалы файдалану мөмкинлеген бирү буенча хезмәтләр күрсәтү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткечләре:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткече | Үлчәү берәмлеге | Төп күрсәткеч дәрәҗәсе | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 20.1.1 | Элемтә челтәрләрен һәм корылмаларын урнаштыру һәм төзү өчен элемтә операторлары тарафыннан кулланыла торган дәүләт һәм муниципаль милек объектлары санын арттыру, 2018 ел күрсәткечләренә карата процентларда | № 1 – элемтә челтәрләрен һәм корылмаларын урнаштыру һәм төзү өчен элемтә операторлары тарафыннан кулланыла торган дәүләт һәм муниципаль милек объектлары өлеше, 2018 ел күрсәткечләренә карата процентларда | процент | 5 | 10 | 15 | 20 | $V = \left(\frac{A}{B} \times 100\%\right) - 100\%$, биредә: A – хисап елында элемтә челтәрләре һәм элемтә корылмалары урнаштыру һәм төзү өчен элемтә операторлары тарафыннан кулланыла торган дәүләт һәм муниципаль милек объектлары саны, берәмлек; | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | В – элемтә челтәрләрен һәм корылмаларын урнаштыру һәм төзү өчен элемтә операторлары тарафыннан фактта файдаланыла торган дәүләт һәм муниципаль милек объектлары саны, 2018 елда, берәмлек | |
| 20.1.2 | «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән киң полосалы файдалану мөмкинлеген бирү буенча хезмәт күрсәтү өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлеше кимүгә юл куймау | № 2 – «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән киң полосалы файдалану мөмкинлеген бирү хезмәте күрсәтү өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлеше | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | $V = \frac{A}{B} \times 100\%$, биредә: А – «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән киң полосалы файдалану мөмкинлеген бирү буенча хезмәт күрсәтү өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар саны, берәмлек; В – «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән киң полосалы файдалану мөмкинлеген бирү буенча хезмәт күрсәтү өлкәсендә барлык формалардагы | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | оешмаларның гомуми саны, берәмлек | |

20.2. Элемтә хезмәтләре күрсәтү, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән киң полосалы файдалану мөмкинлеген бирү хезмәтләре күрсәтү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткеченә ирешү чарасы:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәмлеге | Максатчан индикатор дәрәҗәсе | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 20.2.1 | Дәүләт һәм муниципаль милек объектлары исемлеген актуальләштерү һәм элемтә объектларын һәм корылмаларын урнаштыру мөмкин булган элемтә операторларына, инфраструктура операторларына һәм башка мәнфәгатьле затларга җибәрү | Элемтә операторларына, инфраструктура операторларына һәм башка мәнфәгатьле затларга җибәрелгән белдерүләр саны | берәмлек | 0 | 1 | 2 | 3 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы |
| 20.2.2 | Конкуренцияне үстерү буенча өстәмә чаралар күрү максатында, мәгълүмат-коммуникация | Үткәрелгән сораштырулар саны | берәмлек | 0 | 1 | 2 | 3 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | технологияләре өлкәсендә конкурентлы мохит торышыннан канәгать булу дәрәҗәсен ачыклау өчен, хуҗалык итүче субъектлардан сораштырулар үткәрү | | | | | | | | цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы |

## 21. Ваклап сату базары

Ваклап сату базарының тасвирламасы:

сәүдә Татарстан Республикасы икътисадында иң динамикалы үсүче секторларның берсе булып тора. Татарстан Республикасы Кулланучылар кооперациясе оешмалары берлеге предприятиеләре тарафыннан 895 авыл торак пунктында күчмә сәүдә оештырылган.

2019 елда республика буенча сәүдә мәйданчыкларына көзге авыл хуҗалыгы ярминкәләре кысаларында сату өчен 1,2 млрд. сумнан артык продукция китерелгән. Товарлар китертүдә Казан шәһәрендә 500 артык автомобиль һәм Чаллы шәһәрендә 300 автомобиль эшкә җигелгән.

Ваклап сату базарында барлыкка килә торган проблемалар:

авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре продукциясен сату өчен сәүдә мәйданнарының җитәрлек булмавы,

базарның нык тупланувы һәм эре сәүдә челтәрләренең сатып алучыларга һәм тәэмин итүчеләргә басым ясау мөмкинлеге.

21.1. Ваклап сату базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткече | Үлчәү берәмлеге | Төп күрсәткеч дәрәҗәсе | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 21.1.1 | Татарстан Республикасы шәһәрләрендә һәм район үзәкләрендә, шулай ук | Татарстан Республикасы шәһәрләрендә һәм | Берәмлек | 372 | 373 | 391 | 419 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп | Татарстан Республикасы Авыл |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | торак пунктларда стационар сәүдә объектларыннан башка сәүдә буенча үткәрелгән чаралар санын арттыру | район үзәкләрендә, шулай ук торак пунктларда стационар сәүдә объектларыннан башка күчмә сәүдә буенча үткәрелгән чаралар саны | | | | | | ителми | хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы |

21.2. Ваклап сату базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткеченә ирешү чаралары:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәмлеге | Максатчан индикатор дәрәҗәсе | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 21.2.1 | «Россиянең иң яхшы 100 товары» федераль конкурсында катнашу өчен «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» конкурсын үткәрү | «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» конкурсында катнашучы оешмалар исәбендә «Россиянең иң яхшы 100 товары» конкурсының федераль этабына узган оешмалар өлеше | процент | 59 | 60 | 61 | 62 | $V = \frac{A}{B} \times 100\%$, биредә: A – товарларның кулланучылар төркеме буенча «Россиянең иң яхшы 100 товары» конкурсының федераль этабына узган оешмалар саны, берәмлек; B – товарларның кулланучылар төркеме буенча «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» еллык | «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлеге (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | республика конкурсында катнашкан Татарстан Республикасы оешмалары, шул исәптән житештерүчеләр саны, берәмлек | |
| 21.2.2 | Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә әлеге шәһәрләрнең башкарма комитетлары тарафыннан махсус билгеләнгән стационар һәм стационар булмаган мәйданчыкларда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан үз продукциясен сатуны арттыру чараларын гамәлгә ашыру максатларында ярминкәләр уздыру | Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә үткәрелгән ярминкә чаралары саны | Берәм-лек | 21 | 22 | 23 | 24 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |

## 22. Токымлы терлекчелек базары

Токымлы терлекчелек базарының тасвирламасы:

токымлы терлекчелек базарын үстерү дигәндә, продукт бирүчәнлеге югары булган токымлы терлекләрнең баш санын арттыру һәм, әлбәттә инде, җитештерелә торган продукция күләмен арттыру турында сүз бара. 2020 елның 1 гыйнварына токымлы терлек өлеше 23,3 процент тәшкил итә.

2020 елның 1 гыйнварына кадәр эшчәнлек алып баручы токым үрчетү оешмалары реестрында 70 оешма бар. Базарның гомуми күләмендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлеше 100 процент тәшкил итә.

**Токымлы терлекчелек базарында барлыкка килә торган проблемалар:**
**токымлы терлекчелек базарында катнашучыларга дәүләттән ярдәм җитәрлек дәрәҗәдә күрсәтелми.**

22.1. Токымлы терлекчелек базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткече | Үлчәү берәм-леге | Төп күрсәткеч дәрәҗәсе | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 22.1.1 | Токымлы терлекчелек базарында хосусый милек формасындагы оешмалар тарафыннан сатылган товар күләме кимүгә юл куймау | Токымлы терлекчелек базарында хосусый милек формасындагы оешмалар өлеше | процент | 100 | 100 | 100 | 100 | $V = \frac{V_n}{V_o} \times 100\%$, биредә: $V_n$ – Татарстан Республикасында хосусый милек формасындагы, токымлы авыл хуҗалыгы терлекләре үрчетү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар тарафыннан базарда натурал чагылышта (шартлы күрсәткечтә) сатылган товарлар күләме, мондый оешмалар дигәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | муниципаль берәмлекнең уртак катнашу өлеше 50 проценттан артмаган оешмалар турында сүз бара; $V_o$ – Россия Федерациясенең токымлы авыл хуҗалыгы терлеге үрчетү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы субъектындагы барлык оешмалар (Россия Федерациясе катнашу өлеше 50 проценттан артык булган хуҗалык субъектларыннан, федераль дәүләт унитар предприятиеләрен-нән, дәүләт корпорацияләрен-нән, дәүләт компанияләреннән, федераль бюджет учреждениеләрен-нән, федераль автоном учреждениеләрдән, федераль казна | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | учреждениеләреннән тыш) тарафыннан базарда сатылган товарлар күләме | |

22.2. Токымлы терлекчелек базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткеченә ирешү чарасы:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәмлеге | Максатчан индикатор дәрәҗәсе | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 22.2.1 | Токымлы терлекчелек базарында катнашучыларга ярдәм итүнең гамәлдәге республика программаларын актуальләштерү | Токымлы терлекчелек базарында катнашучыларга ярдәм итү буенча гамәлдәге республика программалары саны | берәмлек | 2 | 2 | 2 | 2 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |

23. Торак төзелеше базары (Торак төзелешенең һәм индивидуаль торак төзелешенең Мәскәү реновация фондыннан тыш)

Торак төзелеше базарының (Торак төзелешенең һәм индивидуаль торак төзелешенең Мәскәү реновация фондыннан тыш) тасвирламасы

Татарстан Республикасы Россия Федерациясе субъектлары арасында торак тапшыру күләме буенча алдынгы урында тора. Соңгы сигез ел эчендә республикада ел саен 2 400 мең кв.метр торак файдалануга тапшырыла.

2010 елдан Татарстан Республикасында җан исәбенә торак тапшыру – 0,6 кв.метрдан да ким түгел. 2019 ел нәтиҗәләре буенча, Татарстанстат мәгълүматларына караганда, җан исәбенә торак тапшыру күрсәткече 0,68 кв.метр тәшкил иткән.

Соңгы биш елда Татарстан Республикасында гамәлгә кертелә торган торак структурасында азкатлы торак төзелеше шактый өлеш алып тора (уртача алганда 41-45 процент) (нигездә – индивидуаль). Казанда бу күрсәткеч шактый түбән һәм 13-17 процент тәшкил итә. Шул ук вакытта азкатлы төзелеш якын-тирә районнарда (Югары Ослан,

Биектау, Зеленодольск, Лаеш, Питрәч районнарында) актив алып барыла.

Татарстан Республикасында 2005 елдан башлап, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, гражданнарны арзанлы һәм уңайлы торак белән тәэмин итү максатларында социаль ипотека системасында торак төзелеше үсештә. Социаль ипотека программасына яшь гаиләләрне, ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, радиация һәлакәтләре һәм катастрофалары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны, Ерак Төньяк районнарыннан күчеп китәргә мәҗбүр булган гражданнарны, инвалидларны, хәрби хезмәткәрләрне һәм башкаларны торак белән тәэмин итү буенча федераль механизмнар кертелгән.

2019 елда Татарстан Республикасында 2 675,5 мең кв.метр торак файдалануга тапшырылган, шул исәптән социаль ипотека программасы буенча – 371,5 мең кв. метр, индивидуаль төзелеш – 1 092,3 мең кв. метр, инвестицияле күпфатирлы торак – 1 211,7 мең кв. метр.

Торак төзелеше базарында (Торак төзелешенең һәм индивидуаль торак төзелешенең Мәскәү реновация фондыннан тыш) барлыкка килә торган проблемалар:

инженерия һәм социаль инфраструктура белән тәэмин ителгән җир кишәрлекләре юк.

23.1. Торак төзелеше базарында (Торак төзелешенең һәм индивидуаль торак төзелешенең Мәскәү реновация фондыннан тыш) конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткече | Үлчәү берәмлеге | Төп күрсәтке дәрәҗәсе | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 23.1.1 | Торак төзелеше өлкәсендә (Торак төзелешенең һәм индивидуаль торак төзелешенең Мәскәү реновация фондыннан тыш) хосусый милек формасындагы оешмалар өлешен арттыру | Торак төзелеше өлкәсендә (Торак төзелешенең һәм индивидуаль торак төзелешенең Мәскәү реновация фондыннан тыш) хосусый милек формасындагы | процент | 99,3 | 99,4 | 99,5 | 99,6 | $V = \frac{V_n}{V_o} \times 100\%$, биредә: $V_n$ – хосусый милек формасындагы оешмалар тарафыннан базарда натураль | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | оешмалар өлеше | | | | | | рәвешендә сатылган товарлар, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү күләме (өлеше), мондый оешмалар дигәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлекнең уртак катнашу өлеше булмаган яки 50 проценттан артмаган хуҗалык субъектлары турында сүз бара; $V_о$ – барлык хуҗалык субъектлары тарафыннан (Россия Федерациясенең катнашу өлеше 50 проценттан артыграк булган хуҗалык субъектларыннан, федераль дәүләт унитар предприятиеләрен-нән, дәүләт корпорацияләрен- | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | нән, дәүләт компанияләрен-нән, федераль бюджет учреждениеләрен-нән, федераль автоном учреждениеләрен-нән, федераль казна учреждениеләрен-нән тыш) базарда натураль рәвешендә сатылган товарлар, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү күләме (өлеше) | |

23.2. Торак төзелеше базарында (Торак төзелешенең һәм индивидуаль торак төзелешенең Мәскәү реновация фондыннан тыш) конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткеченә ирешү чарасы:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәм-леге | Максатчан индикатор дәрәҗәсе | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 23.2.1 | Инновацияле төзелеш материалларын куллануны арттыру | Төзелеш материаллары сәнәгате предприятиеләренең гомуми исәбендә модернизацияләнгән һәм эксплуатациягә | процент | 7,2 | 7,3 | 7,4 | 7,5 | $V = \frac{A}{B} \times 100\%$, биредә: A – модернизация-ләнгән һәм эксплуатациягә | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кертелгән төзелеш сәнәгате предприятиеләре өлеше | | | | | | кертелгән төзелеш материаллары сәнәгате предприятиеләре саны, берәмлек; B – төзелеш материаллары сәнәгате предприятиеләренең гомуми саны, берәмлек | хуҗалыгы министрлыгы |
| 23.2.2 | Торак төзелеше базарында хосусый милек формасындагы оешмалар санын арттыру максатында файдалануга тапшырылган торак күләмен арттыру | Файдалануга тапшырылган торак күләменең үсеш тизлеге | процент | 111 | 111,5 | 112 | 112,5 | $V = \frac{A}{B} \times 100\%$, биредә: A – агымдагы елда торак тапшыру күләме, кв.метр; A – 2018 елда торак тапшыру күләме, кв.метр | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы |

## 24. Торак һәм юл төзелешеннән тыш, капиталь төзелеш объектлары төзү базары

Торак һәм юл төзелешеннән тыш, капиталь төзелеш объектлары төзү базарына тасвирлама:

2020 елның 1 гыйнварына, Татарстанстат мәгълүматларына караганда, тармак реестрында 15 меңгә якын төзелеш оешмасы теркәлгән.

Тармакның тотрыклы икътисадый үсеше шартларының берсе – инвестиция эшчәнлеген активлаштыру. 2019 елда эре һәм урта предприятиеләр буенча төзелешкә юнәлдерелгән инвестицияләр якынча 5,1 млрд.сум тәшкил иткән.

2019 ел нәтиҗәләре буенча «Төзелеш» эшчәнлек төре буенча башкарыла торган подряд эшләренең күләме 363,1 млрд.сум, ягъни 2018 елның гыйнвар–декабрь дәрәҗәсенә карата 98,6 процент тәшкил иткән.

2019 елда «Төзелеш» эшчәнлек төрендәге оешмаларда хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны Татарстан

Республикасының барлык икътисад тармакларында эшли торган 1,278 млн.кеше арасыннан 81,5 мең кеше ягъни республикада эшли торган кешеләрнең гомуми уртача исемлегендәге санының 6,4 процентын тәшкил итә.

Торак һәм юл төзелешеннән тыш, капиталь төзелеш объектлары төзү базарында барлыкка килә торган проблемалар:

төзелеш өлкәсендәге зур административ каршылыклар.

24.1. Торак һәм юл төзелешеннән тыш, капиталь төзелеш объектлары төзү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткече | Үлчәү берәмлеге | Төп күрсәткеч дәрәҗәсе | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 24.1.1 | Торак һәм юл төзелешеннән тыш, капиталь төзелеш объектлары төзү өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлешен арттыру | Проект, төзелеш-монтаж эшләрен, капиталь ремонт һәм җиһаз китертү буенча эшләр башкаруга контрактларның гомуми бәясендә конкурентлы ысул белән барып чыкмаган сатып алулар нәтиҗәсендә төзелгән проект, төзелеш-монтаж эшләрен, капиталь ремонт һәм җиһаз китертү буенча эшләр башкаруга контрактларның бәясе өлеше | процент | 97,9 | 98 | 98,1 | 98,2 | $V = \frac{A}{B} \times 100\%$,<br>бирелә:<br>А – проект, төзелеш-монтаж эшләре, капиталь ремонт буенча эшләр башкаруга һәм җиһазлар китертүгә конкуренцияле ысул белән барып чыкмаган сатып алулар нәтиҗәсендә төзелгән контрактлар бәясе, сум;<br>В – проект, төзелеш-монтаж | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | эшләрен, капиталь ремонт һәм җиһаз китертү буенча эшләр башкаруга контрактларның гомуми бәясе, сум | |

24.2. Торак һәм юл төзелешеннән тыш, капиталь төзелеш объектлары төзү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткеченә ирешү чарасы:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәмлеге | Максатчан индикатор дәрәҗәсе | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 24.2.1 | Лотларны азрак күләмгә бүлү юлы белән Проект, төзелеш-монтаж эшләрен, капиталь ремонт һәм җиһаз китертү буенча эшләр башкаруга дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен заказлар урнаштыру | конкуренцияле ысул белән узмаган дип танылган сатып алулар нәтиҗәсендә төзелгән проект, төзү-монтажлау эшләрен, капиталь ремонт буенча эшләр башкаруга һәм җайланма китертүгә контрактлар бәясенең мондый контрактларның гомуми бәясендәге өлеше | процент | 18,3 | 18,2 | 18 | 17 | $V = \frac{A}{B} \times 100\%$, биредә: A – проект, төзелеш-монтаж эшләре, капиталь ремонт буенча эшләр башкаруга һәм җиһазлар китертүгә конкуренцияле ысул белән барып чыкмаган сатып алулар нәтиҗәсендә төзелгән | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | контрактлар бәясе, сум;<br>В – проект, төзелеш-монтаж эшләрен, капиталь ремонт һәм җиһаз китертү буенча эшләр башкаруга контрактларның гомуми бәясе, сум | |

## 25. Архитектура-төзелеш проектлары базары

Архитектура-төзелеш проектлары базарының тасвирламасы:

Татарстан Республикасының архитектура-төзелеш проектлары базарында үзкөйләнешле өч оешма (алга таба – үзкөйләнешле оешма) эшли:

«Казан проектлаучылар берләшмәсе» үзкөйләнешле оешмасы» ассоциациясе;

«В.П.Логинов исемендәге Идел-Кама архитекторлар һәм проектчылар берлеге» үзкөйләнешле оешмасы;

«Идел-КАМА» архитекторлар һәм проектчылар берлеге үзкөйләнешле оешмасы.

2019 елның 1 гыйнварына әлеге үзкөйләнешле оешмаларда әгъза булып торган оешмаларның гомуми саны – 368, шулардан хосусый милек рәвешендәге оешмалар – 339, бу 92,1 процент тәшкил итә.

2020 елның 1 гыйнварына әлеге үзкөйләнешле оешмаларда әгъза булып торган оешмаларның гомуми саны – 361, шулардан хосусый милек рәвешендәге оешмалар – 352, бу 97,5 процент тәшкил итә.

Архитектура-төзелеш проектлары базарында барлыкка килә торган проблемалар:

кече һәм урта компанияләрнең эре проектларны архитектура-төзелеш проектларына кертү мөмкинлеге чикләнгән;

җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең архитектура-төзелеш проектлавы өлкәсендә квалификациясе түбән.

25.1. Архитектура-төзелеш проектлары базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткече | Үлчәү берәм-леге | Төп күрсәткеч дәрәҗәсе | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 25.1.1 | Архитектура-төзелеш проектлары өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлешен арттыру | Архитектура-төзелеш проектлары өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлеше | процент | 96,85 | 96,9 | 96,95 | 97 | $V = \frac{V_n}{V_o} \times 100\%$, биредә: $V_n$ – хосусый милек формасындагы оешмаларның табыш күләме (өлеше), мондый оешмалар дигәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлекнең уртак катнашу өлеше булмаган яки иң күбе 50 процент тәшкил итә торган хуҗалык субъектлары турында сүз бара; $V_o$ – әлеге базарда барлык хуҗалык субъектлары (Россия Федерациясе катнашу өлеше 50 | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | процenттан артык булган хуҗалык итүче субъектлардан, федераль дәүләт унитар предприятиеләреннән, дәүләт корпорацияләреннән, дәүләт компанияләреннән, федераль бюджет учреждениеләреннән, федераль автоном учреждениеләрдән, федераль казна учреждениеләреннән тыш) табышның гомуми күләме (өлеше) | |

25.2. Архитектура-төзелеш проектлары базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткеченә ирешү чаралары:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәмлеге | Максатчан индикатор дәрәҗәсе | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 25.2.1 | Лотларны азрак күләмгә бүлү юлы белән дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү | Проект эшләрен башкаруга контрактларның | процент | 12 | 11 | 10 | 9 | $V = \frac{A}{B} \times 100\%$, биредә: | Татарстан Республикасы Төзелеш, |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | өчен проект эшләрен башкаруга заказлар урнаштыру | гомуми бәясеннән чыгып, проект эшләрен башкаруга контрактларның конкурентлы ысул белән гамәлгә ашырылмаулары нәтиҗәләре буенча төзелгән проект эшләрен башкаруга контрактларның бәясе өлеше | | | | | | А – барып чыкмаган конкурентлы сатып алу ысулы нәтиҗәсендә төзелгән проект эшләре башкаруга контрактлар бәясе, сум;<br>В – проект эшләрен башкаруга контрактларның гомуми бәясе, сум | архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе (килешү буенча), «Татарстан Республикасы Газлаштыру, энергияне сак тоту технологияләре һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фонды» дәүләт казна учреждениесе (килешү буенча) |
| 25.2.2 | Даими рәвештә җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең | Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең | кеше | 13 | 14 | 15 | 16 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп | Татарстан Республикасы Төзелеш, |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- | --- |
| | архитектура-төзелеш проектлавы өлкәсендә квалификациясен күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрү | архитектура-төзелеш проектлавы өлкәсендә квалификациясен күтәрүгә юнәлдерелгән саны | | | | | | ителми | архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Казан архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү учреждениесе (килешү буенча) |

26. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару базары

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару базарының тасвирламасы:

Татарстан Республикасы минерал-чимал комплексының үсеше белән сыйфатлана торган Россия Федерациясендәге күп булмаган субъектларның берсе булып тора. Татарстан Республикасының җир асты байлыкларында киң таралган файдалы казылмаларның шактый киң спектры бар, алар нигезендә җитештерү оештырылган, Татарстан Республикасы икътисадының төзелештә һәм ком-вакташ катнашмасы, керамик кирпеч, керамзит гравий, төзелеш известе, төзелеш

өчен вак таш, известняк онына баетылган силикат комына ихтыяҗы тулысынча яисә өлешчә тәэмин ителде.

2020 елның 1 гыйнварына җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару өлкәсендә эшчәнлек алып баручы оешмаларның гомуми саны 183 җиткән (181 оешма – хосусый милек формасында, бу базарның гомуми күләменең 98,9 процентын тәшкил итә). 2019 ел нәтиҗәләре буенча алар тарафыннан 11 918,11 мең куб.метр файдалы казылма чыгарылды.

Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару базарында барлыкка килә торган проблемалар:

ятмаларга даими ревизия ясалмау, бу исә гамәлдәге һәм перспективалы чимал базасы турында мәгълүмат алу мөмкинлеген чикли.

26.1. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткече | Үлчәү берәмлеге | Төп күрсәткеч дәрәҗәсе | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 26.1.1 | Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару базарында хосусый милек формасындагы оешмалар өлешен арттыру | Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару базарында хосусый милек формасындагы оешмалар өлеше | процент | 98,1 | 98,2 | 98 ,3 | 98,4 | $V = \frac{V_n}{V_o} \times 100\%$, биредә: $V_n$ – хосусый милек формасындагы оешмалар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару күләме, мондый оешмалар дигәндә, Россия Федерациясе, Татарстан | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы, «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | Республикасы, муниципаль берәмлекнең уртак катнашу өлеше булмаган яки иң күбе 50 процент тәшкил итә торган хуҗалык субъектлары турында сүз бара; $V_o$ – әлеге базарда барлык хуҗалык субъектлары (Россия Федерациясе катнашу өлеше 50 проценттан артык булган хуҗалык итүче субъектлардан, федераль дәүләт унитар предприятиеләрен-нән, дәүләт корпорацияләрен-нән, дәүләт компанияләреннән, федераль бюджет учреждениеләрен-нән, федераль автоном учреждениеләрдән, федераль казна учреждениеләрен-нән тыш) | (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | тарафыннан чыгарылган гомумтаралган файдалы казылмаларның гомуми күләме | |

26.2. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткеченә ирешү чарасы:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикаторы | Үлчәү берәм-леге | Максатчан индикатор дәрәҗәсе | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 26.2.1 | Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылма запасын, аларны дәүләт исәбенә кую өчен, оператив бәяләү | Перспективалы киң таралган файдалы казылма кишәрлекләренең ачыкланган саны | берәмлек | 3 | 4 | 4 | 4 | Абсолют күрсәткеч. Хисаплау методикасы таләп ителми | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы |

## 27. Шәһәр тирәлеген төзекләндерү эшләрен башкару базары

Шәһәр тирәлеген төзекләндерү эшләрен башкару базарының тасвирламасы:

шәһәр тирәлеген төзекләндерү базары ике категориягә бүленә: җәмәгать киңлекләрен төзү һәм төзекләндерү өлешендә дәүләт һәм муниципаль программаларны гамәлгә ашыру буенча эшләр башкару һәм муниципаль берәмлекләрдә төзекләндерү объектларына хезмәт күрсәтү һәм аларны карап тоту буенча эшләр башкару. Югарыда күрсәтелгән категорияләр буенча эшләр аукцион чаралары һәм төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактлары нәтиҗәләре буенча башкарыла.

Шәһәр тирәлеген төзекләндерү базарында эшчәнлек алып баручы хосусый милек формасындагы оешмалар

өлешенә хезмәт күрсәтү базарының гомуми күләменең 41 проценты туры килә.

Шәһәр тирәлеген төзекләндерү эшләрен башкару базарында барлыкка килә торган проблемалар:

муниципаль контрактлар бер елга төзелә, предприятиеләр, милек формасына бәйсез рәвештә, махсус техника паркын яхшырту һәм сатып алуны озак вакытка планлаштыру, киләсе елларга контракт төзү буенча билгесезлек шартларында квалификацияле белгечләрне чакыру яки әзерләү мөмкинлегенә ия түгел;

зур күләмле эшләр һәм залог бәясе югары булган сатуларда конкуренция дәрәҗәсе түбән булу.

27.1. Шәһәр тирәлеген төзекләндерү эшләрен башкару базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

| Т/с | Максаты | Төп күрсәткече | Үлчәү берәмлеге | Төп күрсәткеч өлеше | | | | Төп күрсәткечне хисаплау методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 27.1.1 | Шәһәр тирәлеген төзекләндерү эшләрен башкару өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлешен арттыру | Шәһәр тирәлеген төзекләндерү эшләрен башкару өлкәсендә хосусый милек формасындагы оешмалар өлеше | процент | 41,2 | 41,3 | 41,4 | 41,5 | $V = \frac{V_n}{V_o} \times 100\%$, биредә: $V_n$ – хосусый милек формасындагы оешмаларның табыш күләме, мондый оешмалар дигәндә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлекнең уртак катнашу өлеше булмаган яки иң күбе 50 процент тәшкил итә торган хуҗалык субъектлары | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | турында сүз бара; $V_o$ – әлеге базарда барлык хуҗалык субъектлары(Россия Федерациясе катнашу өлеше 50 проценттан артык булган хуҗалык итүче субъектлардан, федераль дәүләт унитар предприятие-ләреннән, дәүләт корпорацияләрен-нән, дәүләт компанияләреннән, федераль бюджет учреждениелә-реннән, федераль автоном учреж-дениеләрдән, федераль казна учреждениеләреннән тыш) табышының гомуми күләме | |

27.2. Шәһәр тирәлегән төзекләндерү эшләрен башкару базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткеченә ирешү чарасы:

| Т/с | Чараның атамасы | Максатчан индикатор | Үлчәү берәмлеге | Максатчан индикатор дәрәҗәсе | | | | Максатчан индикаторны исәпләү методикасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 27.2.1 | Лотлар бүлеп бирү юлы белән шәһәр тирәлегән төзекләндерү эшләрен башкаруга сатып алу процедураларын үткәрү | Проект, төзелеш-монтаж эшләрен, капиталь ремонт һәм җиһаз китертү буенча эшләр башкаруга контрактларның гомуми бәясендә барып чыкмаган конкурентлы сатып алу ысуллары нәтиҗәсендә төзелгән проект, төзелеш-монтаж эшләрен, капиталь ремонт һәм җиһаз китертү буенча эшләр башкаруга контрактларның бәясе өлеше | процент | 11,8 | 11,5 | 11,4 | 11,3 | $V = \frac{A}{B} \times 100\%$, биредә: A – проект, төзү-монтажлау эшләрен, капиталь ремонт буенча эшләр башкаруга һәм җайланма китертүгә конкуренцияле ысул белән булып чыкмаган сатып алулар нәтиҗәсендә төзелгән контрактлар бәясе, сум; B – проект, төзелеш-монтаж эшләрен, капиталь ремонт һәм җиһаз китертү буенча эшләр башкаруга контрактларның гомуми бәясе, сум | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы, «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе (килешү буенча) |

## 28. Газ (пропан-бутан катнашмасы һәм метан) белән тәэмин итү базары

Газ (пропан-бутан катнашмасы һәм метан) белән тәэмин итү базарының тасвирламасы.

Газлаштыру күрсәткечләре буенча Татарстан Республикасы Россия төбәкләре арасында алдынгы урында тора. 2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасын газлаштыру дәрәҗәсе 99,54 процентка җиткән, шул ук вакытта Татарстан Республикасының характерлы үзенчәлеге – шәһәр һәм авыл торак пунктлары өчен газлаштыру күрсәткечләре тигез дәрәҗәдә югары тәэмин ителгән.

Газдан (пропан-бутан катнашмасы һәм метаннан) төп кулланучылар – дача хуҗалары (сезонлы куллану) һәм пропан-бутан катнашмасында һәм компримацияләнгән табигый газда (метанда) эшләүче транспорт чаралары хуҗалары.

Татарстан Республикасында пропан-бутан катнашмасын сату белән шөгыльләнүче дәүләтнеке булмаган 15 оешма теркәлгән.

Хәзерге вакытта республика территориясендә автомобильләрне газ белән тәэмин итү буенча 24 компрессор станциясе (алга таба – АГНКС) һәм газ белән тәэмин итү буенча 1 җайланма (алга таба – ПАГЗ) урнашкан.

Республикада төзелгән АГНКС челтәренең гомуми проект җитештерүчәнлеге елына 180 000 мең куб. метрдан артык компримацияләнгән табигый газ тәшкил итә.

Россия Федерациясе Президентының мотор ягулыгы сыйфатында табигый газны (метан) куллануны киңәйтү турында 2013 елның 14 маендагы Пр-1298 номерлы, 2018 елның 18 маендагы Пр-743 номерлы йөкләмәләренә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 13 маендагы 767-р номерлы боерыгына ярашлы рәвештә һәм «Энергетиканы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында Татарстан Республикасы Хөкүмәте планлы эш алып бара.

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында 2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба – программа) раслау хакында» 2013 елның 26 апрелендәге 283 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында 2013-2023 елларга Татарстан Республикасында газ-мотор ягулыгы базарын үстерү» дәүләт программасы гамәлгә ашырыла. Программа кысаларында газ-мотор техникасы сатып алу һәм булган техниканы газ-мотор ягулыгына күчерү гамәлгә ашырыла.

Программалар гамәлдә булган чорда республика территориясендә компримацияләнгән табигый газда (метанда)

эшләүче 9 000 якын берәмлек транспорт чарасы файдаланыла.

Газ (пропан-бутан катнашмасы һәм метан) белән тәэмин итү базарында барлыкка килә торган проблемалар:

халык (дачниклар)куллана торган баллоннары торышын тикшерү мөмкинлеге юк;

халыкка көнкүреш шартлары өчен автомобильләрне газ (пропан-бутан катнашмасы) белән тәэмин итү станцияләрендә балоннар тутыру мөмкинлеге бирә торган норматив база юк;

республиканың эре шәһәрләрендә ягулык (метан) салу инфраструктурасы җитәрлек дәрәҗәдә үсеш алмаган.

28.1. Газ (пропан-бутан катнашмасы һәм метан) белән тәэмин итү базарында конкуренцияне үстерүнең төп күрсәткече:

